ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

2023 ел, 27 сентябрь № 113

Җирлекнең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен (вәкаләтләрнең бер өлешен) Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге башкарма комитетының җирле әһәмияттәгемәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының тәкъдимен кабул итәргә:

-җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү;

-җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслашкан хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү;

-җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеген хезмәт күрсәтүләр сыйфатына карата таләпләрне раслау;

-җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау;

-ир яисә хатын, якын туганнары, башка туганнары йә үлгән кешенең законлы вәкиле булмаганда яисә аларның күмү мөмкинлеге булмаганда, үлгән (һәлак булган) мәетне күмү өчен хезмәт күрсәтүләрнең бәясен раслау, шулай ук, үз өстенә күмүне башкару бурычын алган башка затлар булмаганда, эчке эшләр органнары шәхесне билгеләгәннән соң өйдә, урамда яисә башка урында үлгәнне җирләү хезмәте күрсәтүләрнең бәясен раслау;

-Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда эчке эшләр органнары тарафыннан шәхесе билгеләнмәгән үлгән (һәлак булучыларны) җирләү хезмәтләре бәясен раслау.

2.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлеге башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында һәм бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 елларның планлы чорына бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын карауга тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Йомралы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Йомралы авыл җирлеге Башлыгы –
Иске Йомралы авыл җирлеге Советының рәисе Р.А.Муратов